**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.02.2015 № 105-р

Халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру һәм янгын вакытында кешеләрнең үлемен кисәтү турында

1994 елның 21 декабрендәге №69 номерлы "Янгын куркынычсызлыгы турында" Федераль закон нигезендә һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүнең нәтиҗәлелеген күтәрү, янгын вакытында кешеләрнең үлемен кисәтү, янгынга каршы пропаганда үткәрү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Җирле үзидарә органнарына, ТМШ, УК, Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләренә халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне һәм Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары буенча районара ОНД һәм ТР буенча МЧС России Баш идарәсенең профилактик эш буенча районара УНД рекомендацияләре нигезендә янгын куркынычсызлыгы чараларын әзерләүне оештырырга тәкъдим итәргә ( 1 нче, 2 нче кушымта).

2. 2015 елда янгыннарда кешеләрнең үлемен һәм травматизмын кисәтү буенча өстәмә чаралар планын расларга (3 нче кушымта).

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләренә янгын куркынычсызлыгы торышын һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү барышын яктыртырга киңәш итәргә.

4. Килештерү буенча әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Аксубай һәм Нурлат муниципаль районнары буенча районара ОНД начальнигы Н.А. Захаровка һәм Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе урынбасары - "ТР буенча ФПСның 125-янгын бүлеге" ФГКУ башлыгы Курамшин И. И. йөкләргә.

Җитәкче А.К. Габдуллин